| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

10.10.2022 Казан ш. № 922

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү тәртибен раслау хакында» 2012 елның 29 декабрендәге 1044 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү тәртибен раслау хакында» 2012 елның 29 декабрендәге 1044 номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктта «А.Р.Хәсәновка» сүзләрен «Р.Ф.Вәлиулловка» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү тәртибендә:

1.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4 пунктча өстәргә:

4) «рәсми сайт – «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлык эшчәнлеге турында мәгълүматны үз эченә алган сайт, аның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә электрон адресы хокукы Министрлыкка караган домен исемен үз эченә ала.»;

2.1 пунктта «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә» сүзләрен «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрен кулланып» сүзләренә алмаштырырга;

2.11 пунктның сигезенче абзацының беренче җөмләсен киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Әгәр дә бу мәгълүмат массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыкса яки Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылса, Министрлык үз эшчәнлеге турында мәгълүмат бирмәскә хокуклы.».

2. Бу боерык 2022 елның 1 декабреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Министр Э.Ә. Зарипова